Раслыйм
«Сәләт»ТРЯИФ
Генераль директоры
_______ Җ.Ш. Сөләйманов
24 октябрь 2016

«Сәмрух 2016» исемле Республикакүләм сәләтле балалар һәм талантлы яшьләр премиясе нигезләмәсе

## НИГЕЗЛӘМӘ

### 1. Премиянең иганәчеләре һәм оештыручылары.

Татарстан Республикасы «Сәләт» яшьләр иҗтимагый фонды тарафыннан Татарстан Республикасы хөкүмәте ярдәме белән оештырыла.

### 2. Премиянең максаты һәм бурычлары.

Премиянең максаты: Сәләт хәрәкәтендә катнашучы сәләтле балаларны һәм талантлы яшьләрне бүләкләү, Сәләт коллективының, иганәчеләрнең, проектларны оештыручыларның эшенә бәя бирү.

Премиянең бурычлары:

- ел дәвамында Татарстан Республикасы, Рәсәй һәм чит илләрдә Сәләт проектларында катнашып, үз өлешләрен керткән сәләтле балаларны һәм мөгаллимнәрне бүләкләү;
- Сәләт хәрәкәтендә катнашучы балаларда иҗади һәм иҗтимагый активлык дәрәҗәсен арттыру;
- прогрессив фикерләүгә, этник индивидуальлек һәм гомумкешелек сыйфатларына ия булган иҗади-интеллектуаль элитага ярдәм күрсәтү;
- бүгенге җәмгыятьтә интеллект һәм рухны беренче урынга кую идеяләрен алга этәрү;

- Татарстан Республикасы яшь лидерларында позитив, иҗтимагый һәм профессиональ имидж булдыру.

## 3. Премиядә катнашучылар.

Ел саен уздырылучы «Сәмрух 2016» исемле Республикакүләм сәләтле балалар һәм талантлы яшьләр премиясендә Сәләт берләшмәсен актив үстерүче балалар, яшьләр, мөгаллимнәр һәм укытучылар катнаша.

Бер номинациядә җиңү яулаган катнашучы икенче елда шул ук номинациядә катнаша алмый.

Бәйгедә катнашучылар гаризаны бары тик 2 номинациядә генә тапшыра алалар.

## 4. Премияне үткәрү шартлары, тәртибе һәм вакыты.

Премия өч этапта үткәрелә:

1-нче этап – гаризалар кабул итү.

Катнашучылар гаризаны расланган форма белән www.selet.biz сайтында тутыралар һәм портфолиоларын оештыру комитетына җибәрәләр.

Вакыты – **2016 елның 5-нче декабренә** кадәр.

2-нче этап – катнашучыларны сайлап алу. Читтән торып катнашу этабы.

Катнашучыларны читтән торып, портфолио нигезендә сайлап алу.

Вакыты – **2016 елның 6-нчы декабрь - 12-нче декабрь**.

3-нче этап – катнашучыларны әңгәмә нигезендә сайлап алу. Кандидатлар белән әңгәмәне экспертлар советы уздыра, аның төп максаты – катнашучының эшчәнлеге турында тулырак мәгълүмат алу.

Вакыты – **2016 елның 19-нчы декабрь - 2017 елның 30-нчы гыйнвар**.

4-нче этап – тантаналы рәвештә премияне тапшыру.

Вакыты – 2017 елның февраль ае. Әлеге этапның төгәл датасын оештыру комитеты өстәмә хәбәр итәчәк.

Көтелмәгән шартлар килеп чыккан очракта, оештыру комитеты премиянең уздыру этапларын үзгәртә ала.

## 5. Премия номинацияләре һәм билгеләү шартлары.

Ел саен уздырылучы «Сәмрух 2016» исемле Республикакүләм сәләтле балалар һәм талантлы яшьләр премиясе түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

**Номинация: «Ел директоры».**

Номинациядә катнашу өчен мөһим шарт:

- әлеге номинациядә бары тик Сәләт 2016 җәйге профильле аланы директорлары катнаша ала.

Билгеләү шартлары:

- Сәләт берләшмәсе кысаларында казанышларга ия булу;
- Сәләт берләшмәсе эшчәнлегендә актив катнашу;
- Сәләт профильле аланында әйдаманлык тәҗрибәсе туплау;
- номинант җитәкләгән Сәләт профильле аланының уңышлары булу;
- фәнни-тикшеренү эшчәнлеген алып бару;
- массакүләм һәм спорт чараларында катнашу;
- җәмгыять эшендә катнашу;
- шәхси һәм профессиональ уңышларга ия булу;
- Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә дә сөйләшә белү;
- алан базасы идарәчелеге тарафыннан директорлык эшенә югары бәя алу.

Җиңүчеләрне билгеләү өчен ярышның финал өлешендә әлеге номинациядә катнашучыларга бирем бирелә. Биремне хәбәр итү вакыты – премиянең 3-нче этабы. Биремне премияне тантаналы тапшыру этабында үтәргә кирәк була.

**Номинация: «Елның өлкән әйдаманы».**

Номинациядә катнашу өчен мөһим шарт:

- әлеге номинациядә бары тик Сәләт 2016 җәйге профильле аланның өлкән әйдаманнары гына катнаша ала.

Билгеләү шартлары:

- Сәләт берләшмәсе кысаларында казанышларга ия булу;
- Сәләт берләшмәсе эшчәнлегендә актив катнашу;
- Сәләт профильле аланында әйдаманлык тәҗрибәсе булу;
- номинант җитәкләгән Сәләт 2016 профильле аланының уңышлары булу;
- фәнни-тикшеренү эшчәнлеген алып бару;
- массакүләм һәм спорт чараларында катнашу;
- җәмгыять эшендә катнашу;
- шәхси һәм профессиональ уңышларга ия булу;
- Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә дә сөйләшә белү;
- алан базасының идарәчелеге тарафыннан өлкән әйдаманлык эшенә югары бәя бирү.

**Номинация: «Ел аланы».**

Номинациядә катнашу өчен мөһим шарт:

- әлеге номинациядә бары тик Сәләт 2016 җәйге профильле аланнары гына катнаша ала.

Билгеләү шартлары:

- аланда катнашучыларның шәһәр, республика, ил күләмендә казанышларга ирешүләре;

- Сәләт 2016 җәйге профильле алан уздыру өчен смена командасы төзегән махсус методик күрсәтмәләр булу;
- Сәләт 2016 җәйге аланының сыйфаты – сайланган профильгә туры килә (уку-укыту, массакүләм һәм спорт чаралары, укудан тыш программа, идеология – барысы да сменаның профиленә туры килергә тиеш);
- Сәләт 2016 җәйге алан эшчәнлеген район, шәһәр, ил күләмендәге массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту;
- аланның профиль һәм тематик эшчәнлеген ел дәвамында алып бару;
- аланның 2015-2016-нчы елларда ирешкән уңышлары.

**Номинация: «Ел сәлкеше».**

Номинациядә катнашу өчен мөһим шарт:

- әлеге номинациядә 14 яшьтән алып 18 яшькә кадәр булган, 2 ел дәвамында Сәләт хәрәкәтенен үстерүдә актив катнашкан сәлкешләр катнаша ала.

Билгеләү шартлары:

- Сәләт хәрәкәтендә казанышларга ия булу;
- Сәләт хәрәкәтенең эшчәнлегендә актив катнашу;
- югары өлгереш (гариза янына уку урыныннан алынган, соңгы уку елы өчен өлгереш турында белешмә беркетелә);
- Сәләт профильле аланының уңышларында өлеше булу;
- массакүләм һәм спорт чараларында катнашу;
- җәмгыять эшендә катнашу;
- Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә дә сөйләшә белү.

Җиңүчеләрне билгеләү өчен ярышның финал өлешендә әлеге номинациянең катнашучыларына бирем бирелә. Биремне хәбәр итү вакыты – премиянең 3-нче этабы. Биремне премияне тантаналы тапшыру этабында үтәргә кирәк була.

**Номинация: «Сәләт жырлый».**

Номинациядә катнашу өчен мөһим шарт:

- әлеге номинациядә 2015-2016-нчы елларда авторлык җыры катнаша ала.

Билгеләү шартлары:

- шигъри текстның сәнгатьле биеклеге;
- музыкаль текстның оригинальлеге;
- әсәрнең композиция бөтенлеге.

Җиңүчеләрне билгеләү өчен ярышның финал өлешендә әлеге номинациядә катнашучыларга бирем бирелә. Биремне хәбәр итү вакыты – премиянең 3-нче этабы. Биремне премияне тантаналы тапшыру этабында үтәргә кирәк була.

**Номинация: «Ел паблигы».**

Номинациядә катнашу өчен мөһим шарт:

- әлеге номинациядә социаль челтәрләрдәге « Сәләт 2016 » җәйге профильле аланнарның төркемнәре, берләшмәләре, киң таралган социаль битләре катнаша ала.

Билгеләү шартлары:

- кулланучылар/ язучылар саны;
- пабликны рәсмиләштерү/ бизәү;
- кулланучыларның/ язылучыларның эшчәнлеге;
- паблик концепциясенең нәтиҗәлелеге, креативлыгы һәм әһәмияте;
- материалларның әһәмиятлелеге;
- мәгълүматның ышанычлылыгы һәм бастыру ешлыгы;
- материалның оригинал булуы, күчереп алынмаганы һәм тамашачыга тәэсирле итеп бирелүе;
- материалларның Татарстан Республикасының ике телендә дә басылуы.

**Номинация: «Ел әйдаманы».**

- әлеге номинациянең финалистлары «Әйдаман 2016» Республикакүләм «Әйдаманнар ярышы» бәйгесе нәтиҗәләре буенча билгеләнә.
- әлеге номинациянең финалистлары гаризаны 2016-нчы елның 15-нче октябренә, портфолиоларын оештыру комитетына 2016-нчы елның 5-нче декабренә кадәр җибәрәләр.

Калган этаплар нигезләнмәнең 4-нче пунктына карап билгеләнә.

**Номинация «Ел Клубы».**

Номинациядә катнашу өчен мөһим шарт:

- биредә Сәләт берләшмәсе эшчәнлеге тарафыннан 1 елдан да ким эшләмәгән, инде нәтиҗәләре һәм уңышлары булган Сәләт клублары катнаша ала.

Билгеләү шартлары:

- клуб эшчәнлегендә катнашучыларның шәһәр, республика, ил күләмендә казанышларга ия булулары;
- клуб проектларының һәм программаларының гамәлгә ашыру сыйфаты;
- клуб эшчәнлеген район, шәһәр, ил күләмендәге массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту;
- клубның профиль һәм тематик эшчәнлеген ел дәвамында алып бару;
- проект күләме (катнашучылар саны һәм географиясе);
- клубның 2015-2016-нчы елларда ирешкән уңышлары.

## 6. Премиянең оештыру комитеты.

Оештыру комитеты премиянең оештыручыларыннан «Сәләт» клубы әгъзаларыннан, премияне әзерләү һәм уздыру өчен формалаша. Оештыру комитетының составын ТРЯИФ генераль директоры раслый.

Оештыру комитеты:

- премияне оештыруны һәм үткәрүне әзерли;
- премия үткәрүнең һәр этабын администрацияләү;

- премия программасының һәр этабын уздыруны, үткәрүне билгели һәм раслый;
- үткәрү вакытын һәм урынын билгели;
- махсус номинацияләр билгели ала.

## 7. Премиянең экспертлар советы.

«Катнашучыларны сайлап алу» этабын оештыру һәм билгеләү өчен Экспертлар советы булдырыла. Аның составын ТРЯИФ генераль директоры раслый. Экспертлар советының составына Рәсәй Федерациясенең, Татарстан Республикасының хокук чыгаручы, башкаручы хакимият әгъзалары һәм җәмәгать эшлеклеләре керә.

Премиянең экспертлар советы беренче этапка күрсәтелгән ярыш материалларына, өченче этаптагы чыгышка бәя бирәләр һәм премиянең җиңүчесен билгели. Премиянең экспертлар советы махсус бүләкләр һәм номинацияләр билгели ала.

## 8. Гариза тутыруга таләпләр.

Катнашучы гаризасы тутырылган гариза битеннән һәм портфолиодан тора. Портфолио эченә түбәндәгеләр керә:

- тәкъдим итү хатлары, резюме, бәяләмәләр;
- дипломнар, рәхмәт хатлары, мактау грамоталары, сертификатлар;
- иллюстрацияләр (фотосүрәтләр, басма массакүләм мәгълүмат чараларыннан копияләр, видеоматериаллар һ.б.).
- соңгы ике ел эчендә ирешкән уңышларны раслаучы башка кәгазьләр.

Формаль шартлар.

- текст кәгазьләре (кәгазьләр уку өчен аңлаешлы, ачык һәм битнең бер ягына язылырга тиеш);

- катнашучының уңышларын раслаучы кәгазьләр (дипломнарның, рәхмәт хатларының, бүләкләнүләрнең күчерелмәсе, басма массакүләм мәгълүмат чараларыннан копияләр ) булырга тиеш.
- иллюстрация материаллары, гаризалар (фото һәм видео) аерым файлда һәм электрон форматта бирелергә тиеш.

9. Гаризаны бирү тәртибе.

Гариза тапшыру вакыты – **2016 елның 5-нче декабренә** кадәр.

Премиядә катнашу гаризасы оештыру комитетына тапшырыла. Оештыру комитеты адресы: Сәләт йорты, Казан шәһәре, Островский урамы, 23-нче йорт, 3-нче бүлмә.

Белешмә өчен телефон: + 7 (843) 292 - 16 - 00.

Әлеге нигезләнмәгә туры килмәүче гариза иясе ярышка кертелми.

Ярыш материаллары премия нәтиҗәләре билгеле булгач кайтарылырга мөмкин.

Гаризалар саны аз булган очракта, оештыру комитеты гаризалар кабул итү этабын озынайта ала, яки кайсыдыр номинациядә бәйге уздырылмаска мөмкин.